**КПСС райкомы пленумы алдыннан «Дуслык» газетасы битләрендә оештырылган фикер алышуга Норлат разведка бораулавы идарәсе парткомы секретаре Н. А. АЛФЕРОВны чакырдык.**

## • КПСС райкомы пленумына

# Элемтәләр йомшармасын

### (Безнең интервью)

**КОРР. Николай Алексеевич, белгәнегезчә партиянең абруен күтәрү турында сүз һәркайда һәм һәрчак яңгырый. Практик эшчәнлектә моңа ирешү өчен нинди чаралар күрәсез?**

Н. А. А. Иң мөһиме партия членының поручениесе булу, җәмгыять файдасына бәйләнешле берәр эш башкару. Безнең партия оешмасы коммунистларының күбесенең шундый поручениесе бар. Һәм алар бу җәмәгать вазифасын күңел биреп, җаваплылык хисе тоеп башкаралар.

**КОРР. Күп партия оешмаларында аның секретареның роле кимүе хакында сүз алып баралар. Бүгенге секретарьның ролен сез нидә күрәсез? Аның абруен ничек үстерергә мөмкин?**

Н. А. А. Соравыгызны аңлыйм. Әйе, күп нәрсә секретарьның активлыгына да бәйле бүген. Катлаулы шартларда югалып калмаска, коммунистларга һәм партиясезләргә дә практик ярдәм күрсәтү юнәлешендә эзлекле эш алып барырга кирәк.

**КОРР. Бу хакта конкретрак сөйли алмассызмы икән.**

Н. А. А. Бик теләп. Хәзерге моментта эшчеләрнең күбесе социаль ярдәм мәсьәләләре буенча мөрәҗәгать итәләр. Парткомның материаль мөмкинлекләре юк, әлбәттә, ләкин администрация, профсоюз комитеты белән берлектә теге яки бу үтенечне уңай хәл итүгә ирешәбез. Мин предприятие Советы члены да булып торам, күмәк ихтыяҗларны күздә тоткан проблемаларны хәл итүдә катнашам. Болар партия комитетының йогынты көчен саклауга уңай тәэсир итә, билгеле.

**КОРР. Идарә партия оешмасы үзенең сугышчанлыгын бүген дә саклый, димәк.**

Н. А. А. Мин бу мәсьәләдә катгый фикер белдерүдән тоткарланыр идем. Партиядәге кризислы хәл безнең оешманы да читләтеп узмады. Үткән ел 17, быел 5 кеше КПСС сафларыннан чыкты. Партиягә яла ягулар дистәләрчә еллар яшәп килгән кимчелекләрнең барын КПССка гына аударып калдыру коллектив членнары арасында җитәкче партиягә абруй өстәми. Эшчеләрне генә әйтмим, коммунистлар арасында да төрле караш, фикерләр бар.

**КОРР. Бу нәрсә фикерләр плюрализмы буламы?**

Н. А. А. Минемчә, дөрес демократия дигән лозунг астында партиягә һөҗүм, булган-булмаган гаепләрне тагу, яла ягулар. Мәсәлән, Воркута шәһәре Советы рәисе урынбасары коммунистларны асар көн җиткәнне көтеп яшәве турында яза. Кем ул—үзенә күрә демократмы? Демократияне шулай дип күзаллыймы? Шуңа күрә демократия чамадан ашты саныйм. Гуманлылык җитешми, бәхәс культурасы түбән. Демократия мөстәкыйльлек дигән булып дисциплинаны бозу, килешүләрне өзү кебек экономика өчен зарарлы күренешләр ешайды. Мин демократия яклы, ләкин аны мондый бозулар белән һич килешә алмыйм. Производствода закон, тәртип өстенлек итәргә тиеш.

**КОРР. Темадан читкәрәк тайпылдык бугай. Партиянең абруен күтәрү юллары турында сүз алып бара идек бит әле.**

Н. А. А. Хәзер башлангыч партия оешмаларына мөстәкыйльлек бирелде. Бу бер яктан уңай, барысын үзебез хәл итәбез.

**КОРР. Ә икенче яктан?!**

Н. А. А. Артык мөстәкыйльлекнең тискәре йогынтысы да бар, минемчә. Мисал өчен мин партия эшендә яңа кеше, нибары 8 ай гына эшлим. Моны әлеге постта практик тәҗрибәм аз булуын күрсәтү өчен әйтәм. Үткән елгы сайлаулар чорында, гомумән, район партия оешмалары секретарьларының күп өлеше яңарды, яңа кешеләр килде. Билгеле ки, аларның да тәҗрибәсе юк әле. Барыбыз ярдәмгә мохтаҗ. Ләкин безнең өчен бу юнәлештә практик булышлык җитешми, тиешле укыту, өйрәтүләр үткәрелми. Үзебез белгәнчә эшлибез. Уйлавымча, практик ярдәмне һәм контрольне дә көчәйтергә кирәк.

Тагын бер нәрсәгә игътибар юнәлдерәсем килә. Бүгенге көндә кабинет системасы буенча эшләү мөмкин түгел, халык арасында даими булу шарт: аларның да кәефен беләсең, үз хезмәтеңә дә бәяне ишетәсең. Бу райком членнары өчен дә зарури. Һәм аларның күбесе үзе эшләгән коллектив членнары белән аралаша. Әмма райком аппараты работникларына бу җитешми әле, җыелыш яисә башка төрле чара үткәрелмәсә производство участокларында булмыйлар диярлек. Бу хезмәт коллективлары белән элемтәләрнең йомшавын күрсәтеп тора.

Идеология эшенең формалары турында да уйланырга урын бар. Райкомда булганда, киңәшмәләрдә һәм очрашуларда өлкәдән лекторлар сорап кабат-кабат мөрәҗәгать иткәнем бар, тик файдасы тигәне юк. Бүгенге шартларда бу бик зарури, югыйсә.

**КОРР. Әңгәмәгез өчен рәхмәт, Николай Алексеевич.**

Н. А. А. Партоешманың абруен күтәрү турында сөйләгәндә, йомгаклап, тагын бер моментны аерып күрсәтәсем килә: яшьләр белән эшләүгә аерым басым ясау кирәк, кызганычка каршы, бу юнәлештә практик эшчәнлек һәр урында аксый әле. Буыннар арасында элемтәне яңартмый торып авангард булуы бик кыенга туры килер.



ТУГАН ЙОРТ. Н. Туганов фотосы.

## Кайсыгызның күңеле моңлы?...

**Күңелендә иҗат очкыны, каләмен сынап карарга теләге булган, әмма язарга батырчылык итми йөргән газета укучыларыбызны әдәби бәйгегә чакырабыз! Бүген сезгә тәкъдим ителгән бу фоторәсем иҗади омтылышыгызны кабындырып җибәрер дип уйлыйбыз. Фоторәсемгә карап, үзегезнең күңелегез тарткан әдәби жанрда иҗат итә аласыз. Хикәяме, шигырьме, әдәби парча яки берәр хатирәме—ни генә булмасын, әгәр укучыларыбызның күңел кылларына чиртердәй язма була икән—без аны газета битләрендә бастырып чыгарырга вәгъдә итәбез.**

**Конкурска йомгак 1 июльдән соң ясалачак һәм аның нәтиҗәләре газетабызның 60 еллык юбилее алдыннан сезгә дә игълан ителәчәк. Ягез әле, дуслар, кайсыгызның күңеле моңлы, кем үзенең сер-хисләрен иҗат җимешенә әверелдереп безнең белән уртаклаша ала? Сезнең язмаларыгызны көтәбез? Ә конкурста җиңүчеләргә редакциянең истәлекле бүләкләре тапшырылачак.**

**РЕДАКЦИЯНЕҢ ХАТЛАР БҮЛЕГЕ.**

# Укучылар фикере

## Тынычлык һәм уртаклык хакына

Бердәм Союзны саклау мәсьәләсе көн тәртибенә куелганда төрле сүз булды: берәүләр үз принципиальлеген күрсәтеп калырга тырышты, икенчеләре: «Без Союз яклы, тик Россия составында гына булмасын» дигән принциптан чыгып эш итте, башка фикерне ишетергә дә теләмәделәр.

Хәзер, РСФСР Президентын сайлау турында карар кабул ителгәч, Россиядә калуга каршы чыгучылар, аны сайлау безгә нигә кирәк, дип бәхәсләшәләр. Россиядә хәл стабильләшүдән тулаем Союзның язмышы күп бәйле икәне әйтерсең аларга мәгълүм түгел инде. Элекке тоталитар Союз курсын дәвам итү илне котылгысыз рәвештә катастрофага китерер иде. Ә дөрес юлга баскан Россия үзен политик һәм экономик яктан ныгытып, үз членнарын таламый торган яңа ирекле Союзның төп терәге булыр иде.

Сайлаулар мәсьәләсендә мин КПССның Татарстан рескомбюросы формулировкасы белән килешәм. Анда: «...сайлаучылар... тавыш бирү юлы белән үз теләкләрен белдерү мөмкинлеге алырга тиешләр»,—диелә. Әлбәттә, аек фикер йөртүче һәр кеше үзе үк безнең экономиканың, фәннең һәм мәдәниятнең барлык тармаклары бәйләнгән дәүләтнең Президентын сайлауда катнашу хокукыннан файдаланырга омтылырга тиеш. Президент постына үзенең банкротлыкка чыккан «программасы» белән Союзны упкын кырыена китереп җиткергән Рыжков та дәгъва иткәндә моңа битараф карау мөмкинмесоң? Тәкъдим ителгән алты кандидаттан бары тик Б. Н. Ельцин гына утопик коммунизм идеяләреннән арынып җитте һәм кризистан чыгуның реаль планын («500 көн» программасы) тәкъдим итте. Борис Николаевич кандидатурасының төп өстенлеге дип мин аның халык белән бергә материаль кыенлыкларны да тартырга әзерлеген санargyим, ә бүгенге көн өчен бу бик сирәк очрак санала. Октябрь революциясеннән соң илебезнең элекке лидерлары арасында мондый сыйфатларга бары тик Ленин гына ия иде. Экономика өлкәсендә дә ул вакытлар өчен НЭП кыен хәлдән чыгуның кулай варианты булган. Бүгенге көн өчен исә «500 көн» программасы кризистан чыгуның дөрес юлы булып тора. Шулай булгач, без Б. Н. Ельцинга тавыш биреп илебездә хәлне нормальләштерүне тизләтүгә булышлык итәрбез.

Х. ӘХМӘТОВ.
Норлат шәһәре.

## Мөмкинлек булса

Без бу көннәрдә Россия һәм Татарстан республикаларына президентлар сайлау алдында торабыз. Әле алар икесе дә мөстәкыйль республикалар, һичшиксез бирёдә президент сайлау да мөһим адым. Татарстан өчен президент иң элек аның мөстәкыйльлеген, бәйсезлеген яклау өчен кирәк. Әмма суверен республикада Россиягә дә президент сайлау уздырылырга тиешмесоң? Әлбәттә безне моңа мәҗбүр итү артык булыр иде. Мәсәлән, минем өчен, Россиягә президент сайлауның кирәге юк. Ләкин Татарстанда Россиянең язмышына битараф булмаучылар, аның киләчәге өчен борчылучылар да яши бит.

Фәүзия Бәйрәмова РСФСРга президент сайлауга каршы чыгып ачлык игълан иткән иде. Күңел аның яклы, чөнки милләтләр арасында таркаулык хөкем сөргәндә, милләтнең шундый тарафдарлары—бөтен көчен аны яклауга юнәлдергән кешеләр дә кирәк, минемчә. Һичшиксез, бу очракта башка милләтләргә карата бик сак булу мөһим.

Р. ШӘМСЕТДИНОВ,
Мамык урта мәктәбе директоры.

## Авыртмаган башка тимер тарак

РСФСР халык депутатлары съезды 12 июньне ял көне дип игълан итте. Без татарстанлылар өчен дә бу бәйрәм булыр иде, ләкин, сайлаучы буларак, минем күңелдә шик-шөбһәдән башка хәсрәт юк.

ТССРның РСФСР Президентын сайлауга катнашуы борчу салды минем күңелгә. Шуның ике моментын гына аерып күрсәтәм.

Россия башлыгын сайлауны безнең Югары Совет демократларга ташлама ясап кабул итте. 12 июнь көнне алар беренче булып урналар янына килерләр. Икенчеләренә аларга каршы икәнлеген белдереп тавыш бирергә туры киләчәк. Телиме, теләмиме ТССР халкының күпчелеге әнә шул сәбәп аркасында бу кампаниягә кушылачак.

Мәскәүдәге югары постка дәгъвачы кандидатларның берсе дә безгә мөстәкыйльлек вәгъдә итми һәм бу фикерләрен алдан ук, ачыктан-ачык белдереп куйдылар. Без шуны күрә торып, сайлау участокларына мәҗбүри барырга тиеш булабыз. Сайлау узгач безгә, Рәсәй президенты өчен күбегез тавыш бирдегез, аның олтаны астында яшәргә риза булдыгыз, дип җавап бирәчәкләр. Һәм моңа каршы сүз әйтергә безнең җавап булмаячак: алар хак, анда имзаларыбыз торачак ич.

Гомумән ТССР Югары Советының 13 май карары авыртмаган башка тимер тарак булды, сайлауга барырга да бармаска да белмим. Үзебез турында гына уйлап, үзебезгә тиешлесен генә башкарасы иде дә бит. Күршеләр эшенә тыкшынгач, шулай килеп чыкканы билгеле инде аның.

Р. АЙЗАТУЛЛИН.

## Шәймиевны яклап тавыш бирәм

12 июньгә дә күп калмады инде. Бу көнне Татарстаныбыз үз җөмһүриятенә президент сайлаячак. Белмим, ничек үтәр ул...әмма бер нәрсәгә ышанам: президент постын ТССР Югары Советы рәисе Минтимер Шәрипович Шәймиев алыр һәм аны яклап тавыш бирәчәкмен дә. Ул инде үзен эшлекле, энергияле кеше итеп күрсәтте. Киләчәктә тагын да зуррак эшләр көтәбез аңардан. Татарстан бәйсезлеге өчен барган көрәштә М. Ш. Шәймиевның роле әйтеп бетергесез зур буды. Суверенлык мәсьәләсендә уңнан һәм сулдан да басым ясамакчылар аңа. Ләкин Минтимер Шәрипович зирәк акыллылык күрсәтә, мәсьәләне һәр як өчен файдалы булырлык итеп хәл итүгә булыша.

Л. АЛЕКСАНДРОВА.
Норлат шәһәре.

